ҖОМГА
12
МАРТ
1943 ел.
№ 57 (6779)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һәм КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һәм ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ ТАТАРСТАН ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕНӘ КОТЛАВЫ УҢАЕ БЕЛӘН РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘ 11 нче МАРТТА ҮТКӘРЕЛГӘН РАДИОМИТИНГТАН

МОСКВА, КРЕМЛЬ.

Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш СТАЛИНГА

Кадерле атабыз, совет халкының сөекле полководецы Иосиф Виссарионович!

Орденлы Татарстанның хезмәт ияләре безнең халкыбызның фронтка күрсәткән ярдәме өчен Сезнең туганнарча сәламыгызны һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен бөек шатлык һәм гаять зур рухлану белән каршы алдылар.

Сезнең котлавыгызның җылы, онтылмаслык сүзләре Татарстан АССР ның һәрбер колхозчысының һәм колхозчы хатын-кызының, эшчесенең һәм эшче хатын-кызының, һәрбер совет интеллигентының йөрәгенә тирәнтен үтеп керделәр һәм Кызыл Армиягә ярдәмне көн саен, сәгать саен көчәйтүгә, кабахәт немец оккупантларын җиңү өчен үзләренең бөтен көчләрен бирүгә яңа көчле энергия, иҗади энтузиазм, какшамас омтылыш тудырдылар.

Безнең республикабызның хезмәт ияләре Кызыл Армияне коралландыруга һәм оборона фондына 250 миллион сумнан артык акча, фронтовиклар өчен күп җылы киемнәр һәм азыклар җыйдылар, хәрби хезмәткәрләр семьяларына һәм немец оккупантлардан азат ителгән районнарның халыкларына ярдәм итәләр.

Ләкин без, моның әле җитәрлек түгел икәнлеген яхшы аңлыйбыз. Шушы елның 23 нче февралендәге тарихи приказыгызда Сезнең тарафтан ясалган, җиңү белән мавыкмаска һәм масаймаска, дигән акыллы кисәтүне без хәтеребездә тотабыз. «Кызыл Армия алдында мәкерле, рәхимсез һәм хәзергә әле көчле булган дошманга каршы каты көрәш тора. Бу көрәш вакыт сорый, корбаннар сорый, көчләребезне җигүне һәм барлык мөмкинлекләребезне туплауны сорый... Дошман армияләренә куәтле ударлар ясалды, ләкин әле дошман җиңелмәгән. Немец басып алучылар ярсынып каршылык күрсәтәләр, контратакаларга күчәләр, оборона чикләрендә тотынып калырга маташалар һәм аларның яңа авантюраларга барулары мөмкин. Менә шуңа күрә дә безнең сафларыбызда тыныч күңеллелеккә, гамьсезлеккә, масаюга урын булмаска тиеш»,—дип өйрәтәсез Сез.

Сөекле ватаныбыз алдында, һөҗүм итүче Кызыл Армия алдында безнең йөкләмәбез һәм изге бурчыбыз—фронтка ярдәмне тагын да көчәйтү. Ватан сугышының шушы хәлиткеч моментында илебезнең язмышы өчен үзебезнең бөтен җаваплылыгыбызны аңлатан хәлдә, Татарстанның барлык хезмәт ияләре исеменнән без, кадерле Иосиф Виссарионович, Сезгә тантаналы вәгъдә бирәбез:

— Май алды социалистик ярышын киң җәелдерергә. Фронтка ярдәм итү буенча тырышлыкларыбызны ике тапкыр, өч тапкыр арттырырга;

— безнең фабрикаларыбыздан һәм заводларыбыздан фронт өчен коралларны, сугыш припасларын һәм сугыш кирәк-яракларын торган саен күбрәк чыгарырга, хәрби заданиеләрне намус белән һәм үз вакытында үтәргә, планны арттырып үтәү исәбенә Кызыл Армиянең баш командованиесенең махсус фондын төзәргә;

— язгы чәчүгә үрнәк рәвештә әзерләнергә һәм аны югары агротехник дәрәҗәдә үткәрергә, 1943 нче елда югары хәрби уңыш үстерергә, армиягә һәм илебезгә авыл хуҗалыгы продуктларын мөмкин кадәр күбрәк бирергә;

— фронтовиклар семьяларын кайгыртучанлык күрсәтү һәм игътибар белән чолгап алырга, аларга көндәлек ярдәм һәм булышлык итәргә;

— немец оккупантларыннан азат ителгән районнарның халыкларына һәрьяклап ярдәм итәргә;

— Кызыл Армиягә өстәмә көчләрне туктаусыз әзерләргә, халыкны хәрби эшкә өйрәтергә.

Кадерле юлбашчыбыз һәм остазыбыз! Ватаныбызны немец басып алучылардан азат итүнең бөек эше өчен без теләсә нинди сынауларга һәм корбаннарга барырга әзер торабыз. Дошманны җиңү өчен көчләребезне дә, тормышыбызны да кызганмабыз.

Сезгә, туганыбыз һәм сөеклебез иптәш Сталин, кешелек дөньясы хезмәт ияләре шатлыгы өчен сәламәтлек телибез.

Яшәсен безнең җиңүебез!

Яшәсен безнең ватаныбыз!

Яшәсен Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталин!

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы

ТАТАРСТАН АВТОНОМИЯЛЕ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ VI НЧЫ СЕССИЯСЕН ЧАКЫРУ ТУРЫНДА

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Верховный Советының VI нчы сессиясе 1943 нче елның 25 нче мартында Казан шәһәрендә чакырыла.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Президиумы Секретаре өчен—Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе урынбасары Е. АФАНАСЬЕВА.

Казан, Кремль, 10 март, 1943 ел.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

Безнең гаскәрләр Белый шәһәрен алдылар

10 нчы мартта безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, БЕЛЫЙ шәһәрен алдылар (СМОЛЕНСК өлкәсендә).

Кулга төшерелгән трофейларның саны алына.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

10 нчы МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

10 нчы мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Гжатскидан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны, шул исәптән тимер юл станциясе һәм район үзәге Тумановоны алдылар. Безнең гаскәрләрнең ударлары астында чигенүче дошман авыр югалтуларга дучар итепә. Халык яши торган бер пунктка килү юлларында һәм аның урамнарында немецлар үз солдатларының һәм офицерларының 300 дән артык үле гәүдәләрен калдырдылар. Безнең сугышчылар трофейлар кулга төшерделәр һәм пленныйлар алдылар.

Совет очучылары кичә дошманның унлап танкысын, пехота һәм гаскәрләр төялгән 50 дән артык автомашинасын юк иттеләр.

* * *

Харьковтан көньяктарак безнең гаскәрләр дошманның күп санлы танкларына һәм мотопехотасына каршы каты сугышлар алып бардылар. Н-че берләшмәнең частьлары дошманның берничә атакасын кире кайтардылар һәм немецларның 15 танкысын, 4 самоход орудиесен юк иттеләр. Икенче бер участокта гитлерчылар 30 танк ярдәме белән хәрәкәт итә торган бер полк пехотаны һөҗүмгә җибәрделәр. Безнең артиллеристлар һәм гвардеец минометчиклар немецларның 14 танкысын җимерделәр һәм яндырдылар. Сугыш нәтиҗәсендә гитлерчылар 500 гә якын солдат һәм офицерларын югалттылар һәм баштагы позицияләренә алып ташландылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак лейтенант Шайдуров, воентехник Прокопов һәм кече лейтенант Исаков җитәкчелегендәге безнең саперлар группасы төнлә дошман уты астында 650 мина урнаштырды. Саперлар тарафыннан куелган миналарга бәрелеп немецларның 8 танкысы, пехота һәм хәрби йөкләр төялгән берничә автомашинасы шартлады.

* * *

Севскидан көнбатыштарак безнең частьлар халык яши торган бер пунктны алдылар. Дошманның 9 пулеметы, 5 минометы, сугыш припаслары тутырылган бер складны һәм азык тутырылган бер складны безнең кулга төшерелде. Совет танкистлары дошман колоннасына атака ясадылар, 100 дән артык гитлерчыны кырдылар һәм йөкләр төялгән 20 повозканы юк иттеләр.

* * *

Белоруссия районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды февраль аенда немецларның җанлы көчләре, сугыш припаслары һәм азыклар төялгән 6 тимер юл эшелонын юлдан чыгарып аударган. Һәлакәт нәтиҗәсендә 6 паровоз, 69 вагон һәм платформа җимертелгән. Шул ук отряд партизаннарыннан бер группа засададан торып 40 гитлерчыны юк иткән.

* * *

Үзәк фронт участокларыннан берсендә, Германия армиясенең төрле берләшмәләренә караган бер группа солдатлар плен алынды. Немецларның 211 нче дивизиясенең 317 нче полкыннан плен алынган солдат Годфрид Пюллен болай диде: «Русларның һөҗүме башланганчыга кадәр үк инде үзебезнең участокта вакыйгаләр өлгергәнне без томанлы гына булса да сизә идек. Солдатлар, барыннан да бигрәк, чолганышка эләгүдән һәм Сталинград янында юк ителгән 6 нчы немец армиясе язмышын уртаклашудан куркалар иде». Немецларның 208 нче пехота дивизиясенең 338 нче полкыннан плен алынган солдат Курт Шмидт түбәндәгеләрне сөйләде: «Рус артиллериясе безнең оборонабызның күп кенә участокларын «сөреп» ташлады. Артиллерия әзерлеге тәмамланганнан соң рус танклары тоткарлыксыз рәвештә турыдан-туры безнең өстебезгә килделәр. Минем ротаның күпчелек солдатлары һәлак булдылар, ә калганнары пленга бирелделәр. Без Сталинград янында немец гаскәрләренең җиңелгәнлеген ишеттек. Шушы уңай белән кайбер солдатлар: «Немец армиясе бер ел буена гаять зур канлы корбаннар исәбенә яулап алганнарны руслар бер удар белән юкка чыгардылар»,—дип сөйләделәр».

* * *

Франциянең ирекле укчылары Франция крестьяннарыннан немецлар талап алган азыкларны юк итәләр. Уаза департаментында бер складка ут төртелгән һәм анда 900 центнер солы янып беткән. Френуада 600 центнер арыш янып беткән. Патриотлар Гренобльдә немец гаскәрләре өчен билгеләп куелган 180 тонна он әйберләрен бозганнар. Француз патриотлары Вьерзон районында сугыш материаллары һәм азыклар төяп Германиягә бара торган поездны юлдан чыгарып аударганнар. Бу участокта тимер юл хәрәкәте 3 көн туктап торган.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ СЕКРЕТАРЕ ТУРЫНДА

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре хезмәтләрен үтәүне Казан шәһәренең 13 нче номерлы Лозовский сайлау округыннан депутат иптәш Гөлсем Гәрәй кызы Шәмсиевага йөкләргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Секретаре өчен—ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе урынбасары Е. АФАНАСЬЕВА.

Казан, Кремль, 10 март, 1943 ел.

ХРОНИКА

—Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә иптәш Солтан Сәетгәрәй улы Сәетгәрәев Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре хезмәтләреннән азат ителде.

—Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы буенча, иптәш Георгий Анатольевич Кацнельсон, эшне үти алмаганлыктан, Татарстан АССР Совнаркомы янындагы җирле төзү материаллары промышленносте идарәсе начальнигы хезмәтләреннән азат ителде.



Н-че заводның карт эшчесе Камалетдин иптәш Бәдретдинов. Производстводагы уңышлары өчен ул хөкүмәтебез тарафыннан Ленин ордены белән бүләкләнде.

ФРОНТ БРИГАДАСЫ

Бу 20 нче февральдә булды. Яшьләрдән торган фронт бригадасының мастеры иптәш Севастьянов гадәт буенча эшкә бөтен кешедән алда килде. Үз бригадасы членнарына көнлек заданиене аңлатты, һәрберсенә эш бүлеп бирде һәм аны ничек итеп, кайдан башларга күрсәтте.

Эш гадәттәгечә барган кебек иде. Ләкин бригада членнары мастер йөзендә ниндидер борчылу сизделәр.

— Иптәш Севастьянов, сез бүген нигәдер күңелсез,—диде егетләрнең берсе.

—Нигә икәнен менә хәзер сөйләшербез,—диде мастер һәм төшке ял бетәр алдыннан бригаданы үзе янына җыйды.

—Безнең эшләр бик үк шәптән түгел,—диде ул. — Февраль ае бетеп килә инде, ә заданиене үтәүнең очы-кырые күренми әле.

Бригада членнары заданиене үтәмәү куркынычының зур икәнен беләләр иде. Ләкин алар, без гаепле түгел, поставщиклар начар эшләгәч, бер бригада гына нәрсә эшли ала, дип тынычланалар иде.

—Бүгеннән соң безгә берәү дә тоткарлык ясамаячак,— дип дәвам итте мастер. —Эш үзебездән тора. 7—8 көн вакыт калды, шул вакыт эчендә заданиене үтәү өчен һәркем ике тапкыр артык эшләргә тиеш. Аңлыйсызмы?

— Аңлыйбыз,—дип җавап бирделәр бригада членнары бердәм рәвештә.

23 нче февральдә — Кызыл Армия көнендә—иптәш Сталинның тарихи приказы булды. Бу уңай белән иптәш Севастьянов үз бригадасын тагын җыйды.

—Кызыл Армия безнең җиребездән дошманны куып 1.500 километрлы фронт буйлап һөҗүм итә. Без дә тылда фронттагы сугышчылар кебек һөҗүм итик. Февраль заданиесен үтәмичә цехтан чыкмыйк!

Яшь патриотлар февральнең калган көннәрендә аеруча зур күтәренкелек белән эшләделәр. Трушин һәм Калабухов иптәшләр сменасына ике ярымышар норма бирделәр. Хәйруллин, Сафин, Барсуков һәм башкалар заданиене 200 әр процентка үтәделәр.

28 нче февральдә көндез мастер Севастьяновның фронт бригадасы айлык заданиене тәгәлләде.

Төшке аштан соң мастер Севастьянов бригада членнарына яңа задание бирде. Яшьләр яңа дәрт белән бердәм рәвештә эшкә керештеләр. Мастерның йөзендә борчылу күренми иде инде.

О. ИГОРЕВ.

ПЛАН АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ

Чистай шәһәре предприятиеләре һәм артельләре халык өчен киң куллану товарлары җитештерү буенча февраль ае планын Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә—23 нче февральгә —100,2 процент итеп үтәделәр. Казанлылар белән ярышка кушылып алган йөкләмәләрне үтәү йөзендә, планнан тыш 500.000 сумлык күләмдә киң куллану товарлары эшләп чыгарылды.

АНТ ИТӘБЕЗ СИҢА, ЮЛБАШЧЫ:

ФРОНТ ӨЧЕН, ЖИҢҮ ӨЧЕН, НЕМЕЦ ОККУПАНТЛАРДАН ИЛЕБЕЗНЕ ТӘМАМ ЧИСТАРТУ ӨЧЕН КӨЧЕБЕЗНЕ ДӘ, ТОРМЫШЫБЫЗНЫ ДА КЫЗГАНМАБЫЗ!

Татарстан хезмәт ияләренә иптәш Сталинның котлау телеграммасын җибәрүе уңае белән кичә республика күләмендә радиомитинг булды.

Митингны Татарстан АССР Совнаркомы председателе иптәш **Гафиятуллин** ачты. Үзенең кереш речендә иптәш Гафиятуллин орденлы Татарстан хезмәт ияләренең, бөтен совет халкы кебек, бер омтылыш белән — фронтка ярдәмгә бөтен көчләрен һәм барлык средстволарын бирү омтылышы белән яшәүләре турында сөйләде. Иптәш Сталинның рәхмәте безнең республикабызның эшчеләрен, колхозчыларын һәм интеллигенциясен сөекле ватаныбыз хакына яңа батырлыклар эшләүгә рухландыра. Татарстанның хезмәт ияләре дошманны җиңүне тизләтү өчен үзләренең бернәрсәләрен дә кызганмаслар.

Микрофон алдында—Арча районы «Ударник» колхозының агротехнигы иптәш **Низамиева.** Ул болай ди:

— Күпербаш авыл советына караган колхозларның членнары үзләренең дәүләт каршындагы йөкләмәләрен намус белән үтиләр. Без Тамбов өлкәсе колхозчыларының инициативасына чын күңелдән кушылдык. Аз гына вакыт эчендә колхозчылар танклар колоннасы төзелешенә 65.900 сум һәм самолетлар төзелешенә 80.400 сум акча җыеп тапшырдылар. Иптәш Сталинның котлавына җавап итеп без язгы чәчүгә үрнәк булырлык төстә әзерләнергә, югары иген уңышы җыеп алырга, илгә һәм фронтка авыл хуҗалыгы продуктларын тагын да күбрәк бирергә сүз бирәбез.

Аннары Н-че завод стахановчысы иптәш **Косовская** чыга. Иптәш Косовская болай ди:

— Безнең һәрберебез, гвардеец сугышчылар шикелле, үз-үзен аямыйча эшләүгә омтыла. Безнең предприятиедә 11 фронт бригадасы төзелде. Яшь стахановчылар, ашыгыч заказларны үтәгән чакта, үзләренең көчләрен дә, вакытларын да кызганмыйлар. Мин һәм минем иптәшләрем—Решетова һәм Рыжова иптәшләр—продукцияне планда күрсәтелгәнгә караганда 4 тапкыр күбрәк эшләп чыгарабыз.

Дөбъяз районы, «Кызыл Байрак» колхозы бригадиры иптәш **Һадиева** түбәндәгеләрне әйтте:

— Безнең колхоз членнары, Тамбов өлкәсе колхозчыларыннан үрнәк алып, 105.000 сум акча җыйдылар. Бу суммаларга ясалган самолетлар звеносы инде Кызыл Армиягә тапшырылды.

Безнең колхоз язгы чәчүгә бик нык әзерләнә. Бездә чәчүлек орлыклар җитәрлек. Алар чистартылганнар һәм чыгышлары тикшерелгән. Машиналарга тулысынча ремонт ясалган. Агротехника чаралары бик нык үткәрелә. Без күрше колхозларга чәчүлек орлык белән зур ярдәм күрсәтәбез. Моның өчен колхозчылар 120 центнер ашлык һәм 100 центнер бәрәнге бирделәр. Колхоз фондыннан 460 центнер ашлык бүлеп куелды.

Инженер иптәш Кобзарев Н-че завод коллективының данлыклы эшләре турында сөйли:

— Иптәш Сталинның котлавы безнең һәрберебездә яңа көчләр тудырды. Завод коллективы, бөек Беренче Май бәйрәмен лаеклы рәвештә каршыларга хәзерләнеп, март һәм апрель айларында планнан тыш бер партия сугыш продукциясе эшләп чыгарырга һәм аны Баш Командованиенең махсус фондына тапшырырга карар бирде.

Аннан соң сүз Бауман районының фронтовиклар хатыннары советы председателе иптәш **Афанасьевага** бирелә. Ул болай ди:

— Минем улым фронтта геройларча һәлак булды. Мин үзем карт инде, ләкин совет халкына китерелгән барлык газапланулар өчен фашист ерткычлардан үч алу юлында кулымнан килгәннең бөтенесен эшләргә тырышам.

Хәрби часть вәкиле иптәш **Зимуров,** Татарстанның хезмәт ияләрен, совет сугышчыларының, бөтен совет халкы ярдәме белән, үзләренең бурычларын намус белән үтәячәкләренә, дошманны тар-мар итәчәкләренә һәм ватаныбыз чикләреннән куачакларына ышандырды.

Митингта, шулай ук, Биектау районының Буденный исемендәге артель председателе **Аристов,** Н-че завод стахановчысы **Вәлиәхметов,** язучы **Кави Нәҗми** иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Митингның ахырында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Колыбанов** речь белән чыкты. Иптәш Колыбанов болай диде:

— Иптәш Сталинның безнең республикабыз хезмәт ияләренә җибәргән котлавы һәм Кызыл Армиянең рәхмәте безнең барлык эшчеләребезне, колхозчыларыбызны, интеллигенцияне фронтка тагын да күбрәк ярдәм итүгә рухландыра.

Безнең илебездә Беренче Май алды социалистик ярышы куәтле дулкын булып җәелә. Республикабызның предприятиеләре, бу бөтен халык хәрәкәтенә кушылып, производство заданиеләрен үтәү белән генә калмаска, бәлки Кызыл Армиянең Баш Командованиесенең махсус фондына планнан тыш продукция дә бирергә тиешләр.

Хәзер безнең республикабызның колхозлары, совхозлары һәм МТС лары язгы чәчүгә әзерлекнең иң җаваплы чорында торалар. Чәчүлек орлыклар җыярга һәм әзерләргә, тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясарга, кадрлар әзерләргә—менә болар язгы чәчүне уңышлы үткәрүнең шартлары. Безнең республикабыздагы барлык колхозларның, барлык колхозчыларның бурычы—язгы чәчүгә үрнәк булырлык төстә әзерләнү өчен урында булган мөмкинлекләрнең бөтенесеннән тулысынча файдалану.

Икмәк тә шулай ук Кызыл Армия өчен корал икәнлекне истә тотарга кирәк, һәм без, тыл работниклары, аны Кызыл Армиягә җитәрлек кадәр санда бирергә тиешбез.

Быел язгы чәчү катлаулы һәм авыр шартларда үтәчәк, ләкин без бу авырлыкларны большевикларча җиңәргә һәм алдыбызга куелган бурычны намус белән үтәргә тиешбез.

Республикабызның хезмәт ияләре Кызыл Армиягә ярдәмнең барлык төрләрен көчәйткәннән-көчәйтә барырга тиешләр. Шулай ук без фронтовиклар семьялары турында кайгырту Кызыл Армия турындагы безнең бөтен кайгыртуыбызның яртысы икәнлекне истә тотарга тиешбез.

Бөтен көч—дошманны тар-мар итүгә, бөтенесе — фронт өчен! Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинның котлавына һәм рәхмәтенә безнең җавабыбыз әнә шул булырга тиеш.

Митингта катнашучылар иптәш Сталинга котлау хаты җибәрделәр.

ЗУР ОЕШКАНЛЫК

Верховный Баш Командующий Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинның Татарстан хезмәт ияләренең «Советлар Татарстаны» исемле сугыш самолетлары эскадрильялары төзелешенә 100 миллион сум акча тапшырулары уңае белән котлап биргән телеграммасын баш инженеры иптәш Кадышев булган завод коллективы алкышлап каршы алды. Митингларда чыгып сөйләүчеләрдән Александрова, Попова, Никитина һәм башка иптәшләр даһиебезнең котлавына эш белән җавап бирәчәкләрен белдерделәр.

Алдынгы стахановчы иптәш Александрова үзенең чыгышында болай диде:

— Иптәшләр, минем ирем фронтта фашистик ерткычларны тар-мар итә. Ә, мин тылда фронтка кирәк булган продукцияне җитештерәм. Февраль ае планын 200 процент итеп үтәдем, март планын 300 процент итеп үтәргә сүз бирәм. Үзем белән ярышка корпусыбызның барлык эшчеләрен чакырам. Безнең продукциябез гитлерчы кабахәтләрне тизрәк юк итүгә ярдәм итәчәк.

Митингта катнашучылар Кызыл Армиягә ярдәмне тагын да арттырырга, март ае планын срогыннан алда арттырып үтәргә, продукциянең үзенә төшү бәясен киметергә конкрет йөкләмәләр алдылар.

ЯҢА КӨЧ, ЯҢА ДӘРТ БЕЛӘН!

Цехта бүген җанлылык аеруча көчле.

— Иптәш Сталин безгә үзенең туганлык сәламен җибәрә һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен белдерә!

Барлык телләрдә әнә шул шатлыклы сүзләр кабатлана. Алар эштә яңа көч, яңа дәрт тудыралар. Йөрәкләр ешрак тибә, куллар җитезрәк хәрәкәт итә, машиналар тагын да кызурак әйләнәләр.

Митингта беренче булып мастер Кочетов чыгыш ясады.

— Иптәш Сталинның сәлам һәм рәхмәт телеграммасы,—ди ул,—безне яңа җиңүләргә рухландыра. Без производствода хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да югарырак күтәрергә, фронт өчен дәһшәтле коралларны тагын да күбрәк бирергә тиешбез. Без эшләп чыгара торган продукция дә, танк колонналары һәм сугышчан самолет эскадрильяләре төзү өчен керткән саклык акчаларыбыз да, фронтовиклар семьялары турында эшлекле кайгыртучанлык күрсәтүләребез дә—барысы да явыз дошманны тар-мар итү көнен якынайталар. Бу тармакларның һәркайсы буенча тагын да күбрәк энергия белән эшләргә бездә мөмкинлекләр бик күп әле. Бу киң мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланып, иптәш Сталинның телеграммасына лаеклы рәвештә җавап бирик.

Митингта чыгып сөйләгән Михайлов һ. б. иптәшләр дә шул ук бердәм фикерне кабатладылар.

Н-че заводның начальнигы иптәш Фридман булган цехында бу көннәрдә яңа, искиткеч куәтле патриотизм туды. Барлык коллектив эштә тырышлыкны күп тапкыр арттыра. Фронттагы җиңүләр белән, бөек полководецыбыз иптәш Сталинның сәлам һәм рәхмәт телеграммасы белән тирән рухланган хәлдә цех тулы килеш планны кичә 140 процентка үтәде.

Митингтан соң, стахановчы Тиханов һәм участок мастеры Грузанов иптәшләр, ВКП(б) сафларына кандидат итеп алуны сорап, партоешмага гариза бирделәр.

ХЕЗМӘТ ЭНТУЗИАЗМЫ

Казан шәһәренең «Швеймехпром» артеле членнары һәм хезмәткәрләре фронтка һәм илгә продукция җитештерүне арттыру өчен үз-үзләрен аямыйча эшлиләр. Артель январь һәм февраль айларында производство планын срогыннан элек арттырып үтәде. Шул исәптән киң куллану товарлары эшләп чыгару планы 157 процент итеп үтәлде.

Шуның өстенә, артельнең членнары, соңгы берничә атна эчендә самолетелар эскадрильясе төзү фондына 22.132 сум акча, фронтовикларга 6.000 сумлык җылы киемнәр һәм башка бик күп бүләкләр туплап тапшырдылар.

Советлар Союзы Маршалы, Дәүләт Оборона Комитеты Председателе иптәш Сталинның Татарстан хезмәт ияләренә җибәргән котлавы артельчеләр арасында хезмәт энтузиазмы дулкынын тагын да күтәрде. Шул уңай белән ясалган митингта артельнең культсовет председателе иптәш Барашева болай диде:

— Бөек юлбашчының котлавы һәм ватан сугышы фронтларында Кызыл Армиянең уңышлы һөҗүме безне тагын да яхшырак эшләүгә рухландыра. Фашист җыланнарны тәмам тар-мар итү өчен без бөтен көчебезне биреп эшләрбез һәм производство планнарын системалы рәвештә арттырып үтәрбез.

Митингта катнашучылар аның сүзләрен алкышлап каршыладылар. Бер тавыштан кабул ителгән резолюциядә артель коллективы беренче квартал производство планын 25 нче мартка үтәп чыгарга, фронтка һәм гражданнар халкына тик яхшы сыйфатлы гына продукция бирергә йөкләмә алды.

АЗАТ ИТЕЛГӘН РАЙОННАРГА

Татарстан элемтәчеләре азат ителгән өлкәләргә һәм районнарга ярдәм итүдә актив катнашалар. Рәсемдә: Казан телеграфы инженеры М. М. Райтблат азат ителгән районнарга җибәрү өчен җыелган приборларның төзеклеген тикшерә.

И. Папков фотосы.

КОМСОМОЛ ТОРМЫШЫ

ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕ КӨЧӘЙТЕРГӘ

Партия оешмалары тарафыннан комсомолга большевистик җитәкчелек тәэмин ителгән урыннарда, яшьләр арасында политик-тәрбия эшләрен җәелдерү, эшкә яңа күтәрелгән яшь кадрларны тәрбияләү, аларны практик эшкә өйрәтү дә яхшы оештырылган. Мәсәлән, Таш Чишмә авылындагы башлангыч партоешма комсомол эшенә ныклы игътибар бирә. Шуның нәтиҗәсендә, биредә комсомолецлар һәм яшьләр колхоз производствосында, җәмәгать тормышында активлык күрсәтәләр. Алдынгы яшьләр хисабына комсомол сафлары үсә. Монда 1942 нче елда ВЛКСМ сафларына 15 кеше кабул ителгән. Иске Өҗем, Ашытбаш авыл партия оешмалары да комсомолга конкрет җитәкчелек итәләр, көндәлек эштә практик булышлык күрсәтәләр.

Ләкин, безнең районда кайбер башлангыч партоешмалар комсомолга җитәкчелек итүдә ВКП(б) уставы таләпләрен үтәүдән ерак торалар әле. Хатнә авыл партоешмасы комсомол эше белән бөтенләй шөгыльләнми. Аның секретаре авылда кемнәрнең комсомол икәнен дә белми. Комсомолецлар, колхоз производствосында һәм җәмәгать тормышында активлык күрсәтмиләр. Апас һәм Кызыл яр авылларындагы партоешмаларның да комсомолга җитәкчелекләре бик йомшак. Чембулат авылындагы комсомол оешмасының секретаре булып коммунист иптәш Мөхетдинова эшли. Ул үзенең эшенә җавапсыз карый, яшьләр арасында политик-тәрбия эшләре алып бармый.

Комсомолга җитәкчелек итү буенча парооешмалар эшендәге кимчелекләрне бетерүдә ВКП(б) райкомының да таләпчәнлеге җитәрлек түгел.

Бу кимчелекләр ашыгыч рәвештә бетерелергә, комсомолга җитәкчелек итү ВКП(б) уставы таләпләренә җавап бирерлек итеп оештырылырга тиеш.

А. САФИУЛЛИН,
ВКП(б) ның Кызыл юл райкомы инструкторы.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

ЭШЛЕКЛЕ ҖАВАП

БАЛТАЧ, 11 март. (Телефон буенча). «Яңа ил» колхозы членнарының мөрәҗәгатен районның барлык колхозларында да зур активлык белән тикшерделәр. «Кызыл яшьләр» колхозында шушы уңай белән үткәрелгән җыелыш бигрәк тә җанлы үтте. Колхозның стахановчысы Нәсимә иптәш Садыйкова үзенең чыгышында:

— Безнең колхозыбызда чәчүлек бәрәңге орлыгы җитешми, ә без аны үзебез дә таба алабыз. Мин үз хуҗалыгымнан колхозга 12 пот бәрәңге бирәм һәм үзем белән тиңләшергә башка иптәшләрне да чакырам,—диде.

Колхозчылар иптәш Садыйкованың инициативасын алкышлап каршы алдылар. Шул җыелышта ук Хәтирә Абдрахманова, Гөлбикә Гарифуллина иптәшләр колхозга 9 ар пот, Хәким иптәш Гыйбадуллин 6 пот бәрәңге орлыгы бирәчәкләрен әйттеләр. Шул көнне үк колхозчылар 400 потка якын бәрәңге җыып колхозга тапшырдылар.

Районыбызның башка колхоз членнары да «Кызыл яшьләр» колхозы членнарыннан үрнәк алалар. «Яңа тормыш» колхозы членнары 300 пот, «Кызыл Татарстан» колхозы членнары 210 пот, «Кызыл октябрь» колхозы членнары 180 пот бәрәңге орлыгы бирделәр.

Район буенча бары ике көн эчендә генә дә 2.000 потка якын бәрәңге орлыгы җыелды.

«Вильтурис» колхозы членнары үз хуҗалыкларындагы запастан колхозга бурычка 133 центнер бөртекле орлык бирделәр. «8 нче март», «Берек» «Комсомол» һәм «Кызыл тау» колхозы членнары үзләреннән арткан ашлыктан күрше колхозларга чәчүлек орлык җыеп бирүне оештырдылар.

Г. ГАЙНЕТДИНОВ

ОРЛЫК ӘЗЕР

Безнең колхоз үткән елны кырчылык буенча да һәм шулай ук терлекчелек буенча да бирелгән планнарны шактый арттырып үтәде. Иген уңышы яхшы булды. Нәтиҗәдә без Кызыл Армиябезгә күп кенә ярдәм иттек. Кызыл Армия фондына 180 центнер һәм фронтка ярдәм тәртибендә 300 центнер ашлык, 15 центнер ит, 20 потка якын йон һәм башка күп кенә продуктлар тапшырдык.

Хәзер без, язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгына кушылып, эшне берничә тапкыр көчәйттек. Машиналарга, сбруйларга ремонт ясау тәмам булды. Чәчү орлыкларыбызның торышы белән мактана алабыз: алар һәрьяктан югары кондицияле. Орлык барлык чәчү мәйданын капларга җитә.

Г. ГАЙНУЛЛИН.
Октябрь районы, «Үрнәк» колхозы председателе.

„ЯҢА ЮЛ“ КОЛХОЗЫ ЧЛЕННАРЫ ЙӨКЛӘМӘСЕ

ШӨГЕР, 11 март. (Үз хәбәрчебездән, телефон буенча). «Яңа юл» колхозында язгы кыр эшләренә әзерлек башка колхозларга караганда артта бара. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау тәгәлләнеп бетмәгән. Кышкы агротехника чараларын үткәрү йомшак оештырылган. Атларны тәрбияләү, аларга сбруйлар әзерләү канәгатьләнерлек түгел.

Колхозчыларның үткәрелгән соңгы җыелышы нәк менә шул мәсьәләләргә багышланды. Җыелышта ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарларын, Апас районы, «Яңа ил» колхозы членнарының мөрәҗәгатен өйрәнгәннән соң колхозчылар югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләрне бик тизлек белән бетерү, чәчүне тулы әзерлек белән каршылау өчен практик чаралар билгеләделәр. Колхозчылар, быел һәр гектардан кимендә 100 пот уңыш алырга, оборона фондына планнан тыш 3.660 пот ашлык тапшырырга, оборона фондына махсус рәвештә 10 гектар ашлык чәчәргә, язгы чәчүне 7—8 көндә тәгәлләргә йөкләмә алып, «Кызыл орден» колхозын социалистик ярышка чакырдылар. Моның өчен, «Яңа ил» колхозы членнарының тәкъдиме нигезендә,чәчүгә әзерлекне тәгәлләү буенча фронт айлыгы игълан ителде. Хәзер колхозда билгеләнгән бу чараларны үтәү өчен көрәш җәелдерелде. Бригадирлар арасында үзара социлистик ярыш договорлары төзелде. 4 нче бригада бригадиры иптәш Гайсин шунда ук беренче бригада бригадиры иптәш Зиятдиновны ярышка чакырды. Иптәш Гайсин бригадасы язгы чәчүгә әзерлектә колхозда беренче урында бара. Аның бригадасы машиналарга, инвентарьга ремонтны күптән тәгәлләде. Ул язгы кыр эшләренә кирәкле арбаларны да әзерләп куйган.

Райондашлар әзеннән

АПАС,11 март. (Махсус хәбәрчебездән, телефон буенча). Ленин исемендәге авыл хуҗалыгы артеле членнары өчен райондашлары «Яңа ил» колхозы членнарының мөрәҗәгате язгы чәчүгә әзерлекне көчәйтүдә зур этәргеч булды. Бу мөрәҗәгать урнаштырылган газеталар килеп җитү белән үк агитаторлар бригадаларга киттеләр. Колхозның барлык эш участокларында митинглар булды. Колхозчылар алда торган бурычлар һәм аларны уңышлы үтәү өчен нәрсәләр эшләргә кирәклек турында сөйләштеләр. Колхозның стена газетасы «Авангард» та фронт айлыгына багышлап чыгарылды. Газетаның редакторы иптәш Сәмигуллина бригадаларда чыга торган газеталарның да чираттагы номерларын әнә шуннан чыгып планлаштыру турында редакторлар белән сөйләште.

Колхоз председателе иптәш Хәйруллин:

— Фронт айлыгында эшлисе эшләр күп. Чәчүлек орлыкны чистартып бетерәсе бар. Тирес чыгару планы да 80 процентка гына үтәлгән. Колхозчыларны язгы эшләргә өйрәтү буенча да эшлисе эшләребез аз түгел,—диде.

Шулай фикер алышканнан соң правление утырышы чәчүлек орлыкларны чистартуны, алмаштырыласыларын алмаштыруны, тирес чыгаруның кышкы планын үтәүне, колхозчыларның хуҗалыкларында көл, кош тизәкләре өчен коры урыннар әзерләп, аларны бер урынга җыюны 20 нче мартка тәгәлләргә, чәчү вакытында кемнең кайда һәм нинди эш башкаруын билгеләп, бу турыда колхозчыларга яхшылап аңлатырга дип карар чыгарды.

Колхоз правлениесе фронт айлыгында башкару өчен тагын күп кенә чаралар билгеләде. Эшнең үтәлешен тикшереп тору һәм булышу өчен аерым эш участокларына правление членнары беркетелде. Хәзер колхозчылар правление тарафыннан билгеләнгән чараларны үтәү өчен тырышып эшлиләр. Фронт айлыгы башлану белән бу колхозда язгы чәчүгә әзерлек эшләре сизелерлек рәвештә көчәйде.

ПЛАН АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ

Арча районының «Комбайн» колхозы 509 гектар урынына 879 гектарда кар тотты, 200 центнер урынына 235 центнер көл җыйды. Язгы чәчү вакыты өчен 59 сука камыты кирәк иде. Бу план да арттырып үтәлде: 60 камыт әзерләнде.

Ш. ГАЛИЕВ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

10 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

10 нчы мартта безнең гаскәрләр һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, Смоленск өлкәсендәге Белый шәһәрен алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

9 нчы мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 20 гә якын танкларын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 дән артык автомашиналарын юк иттеләр яки зарарладылар, 3 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар һәм бер сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Сычевкадан көньяктарак һәм көньяккөнбатыштарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдереп, халык яши торган 20 дән артык пунктны алдылар. Безнең частьлар район үзәген һәм тимер юл станциясен Новодугиноны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 10 танк, 4 орудие һәм бер сугыш припаслары складына бар. Гжатскидан көньяк-көнбатыштарак дошман бер оборона чигендә совет гаскәрләренең һөҗүмен бик тырышып тоткарларга маташты. Бик каты сугышлар нәтиҗәсендә безнең частьлар дошман оборонасы линияләрен өзделәр һәм, алга таба барып, халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар.

* * *

Оленинодан көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә дистә пунктны немецлардан азат иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Халык яши торган бер пунктны алган чакта безнең сугышчылар немецларның бер батальон пехотасын тар-мар иттеләр, 6 танк, 8 орудие һәм бер сугыш припаслары складын кулга төшерделәр.

* * *

Харьковтан көньяктарак һәм көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманның бик күп танкларының һәм пехотасының бик көчле атакаларын кире кайтардылар. Бер участокта безнең оборонабызның алгы кырыена якынлашкан дошман танкларына яшереп куелган орудиеләрдән ут ачылды. Немецларның 9 танкысы юк ителде, ә калганнары тиз генә качтылар. Икенче бер участокта Н-че берләшмә частьлары, гитлерчыларның атакаларын кире кайтарган чакта, 800 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар, дошманның 26 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар.

* * *

Ильмень күленнән көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че берләшмә частьлары сугышларның ике көне эчендә 15 орудие, 12 миномет, 56 пулемет, меңнән артык винтовка, 12.000 снаряд һәм мина, 11.000 нән артык граната, 210.000 патрон, 160 яшик дары, 50 километрдан артык телефон кабеле, 3 радиостанция һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Дошман гаять күп җанлы көчләрен югалтты.

* * *

Кубаньда безнең частьлар, гитлерчыларның каты каршылык күрсәтүен бастырып, район үзәге Красноармейсканы. һәм халык яши торган күп кенә башка пунктларны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды март башында зур бер тимер юл станциясе поселогына урнашкан немецлар гарнизонына кинәт һөҗүм ясаган. Совет патриотлары, сакчыларны үтереп, немецларның станциядә булган 11 вагоннан торган бер эшелонын шартлатканнар һәм бер ягулык складын яндырганнар, 5 километр озынлыкта тимер юлны җимергәннәр. 119 винтовка, 2 станоклы пулемет һәм күп кенә патроннар кулга төшерелгән. Партизаннар 97 совет гражданын төрмәдән азат иткәннәр. Бу кешеләрне гитлерчылар, Германия властьларының боерыкларын үтәмәгән өчен, атарга хөкем иткән булганнар. Украинаның икенче бер отрядының бер группа партизаннары немецларның жандарм идарәсен тар-мар иткәннәр. Немецлар тарафыннан Германиягә озату өчен әзерләп куелган 220 тонна ашлык халыкка өләшеп бирелгән.

* * *

Немецларның 337 нче пехота дивизиясенең 668 нче полкының 8 нче ротасыннан пленга алынган солдат Ян Данилевский болай диде: «Әзштарак офицерлар Гжатск—Ржев — Вязьма районының стратегик яктан зур әһәмияте бар, һәм шунлыктан халык яши торган һәрбер пунктны ничек кенә итеп булса да саклап калырга кирәк, дигәннәр иде. Хәзер инде, без русларның басымы астында чигенә башлагач, командование сводкаларында план тәртибендә күчү һәм фронт линиясен тигезләү турында әйтелә. Бер унтер-офицер, күңелләре төшкән солдатларны рухландыру өчен, болай диде: «Чигенү, хәтта тәртипсез чигенү булса да, чолганып алынуга караганда һаман да яхшырак».

Совет Информбюросыннан

11 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

11 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Гжатскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Халык яши торган бер пункт районында немецлар контратакага күчкәннәр иде. Н-че часть сугышчылары, контрудар ясап, гитлерчыларны аударып ташладылар һәм, чигенүче дошманның артыннан барып, халык яши торган пунктка бәреп керделәр һәм аны алдылар. 8 орудие, 12 пулемет һәм бер сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Темкинодан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак, төнге сугышлар нәтиҗәсендә, халык яши торган берничә пункт, шул исәптән Исаково тимер юл станциясе алынды.

* * *

Харьковтан көньяктарак безнең гаскәрләр сан ягыннан өстен булган дошман көчләренә каршы бик каты сугышлар алып бардылар. Халык яши торган бер зур пунктта безнең сугышчылар бер батальон немец автоматчикларын һәм зур бер танклар группасын чолгап алдылар. Безнең подразделениеләр, чолганыш боҗрасын кысып, дошманның 15 танкысын юк иттеләр һәм 400 гә якын гитлерчыларны кырып ташладылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак бер участокта немецлар безнең позицияләргә атака ясаганнар иде, ләкин барлык корал төрләре уты белән алып ташландылар. Сугыш кырында дошманның 100 дән артык үле гәүдәләре калды. Мылтык һәм пулемет уты белән немецларның 2 самолеты атып төшерелде.

* * *

Льговтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр бер тимер юл станциясе өчен булган сугышта 300 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Дошманның 2 танкысы, 6 орудиесе, 19 пулеметы һәм төрле йөкләр төялгән 14 автомашинасы кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең разведчиклар, дошман тылына барып чыгып, ягулык тутырылган бер тимер юл составын яндырдылар. 8 цистерна һәм берничә вагон янды.

* * *

Калинин өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды март башында немец-фашист басып алучыларның бер гарнизонына һөҗүм иткән һәм 30 гитлерчыны кырып ташлаган. Партизаннар трофейлар кулга төшергәннәр, шулай ук немецлар тарафыннан халыктан талап алынган атларны һәм сыерларны халыкка кайтарып биргәннәр. Икенче бер отрядның партизанчары бер тимер юл күперен шартлатканнар. Тимер юлның бу участогында поездлар йөреше тукталган.

* * *

Орел өлкәсе, Унеча шәһәренә февральаенда, немецлар сакчылыгы астында, Россиядә сугышудан баш тарткан итальян солдатлары төялгән ике эшелон килгән. Немецлар үз «союзникларын» төрлечә мыскыллаганнар һәм кыйнаганнар. Икенче көнне гитлерчылар бер группа итальян солдатларын сайлап алып, аларны шәһәр мәйданында асып үтергәннәр.

* * *

Немец-фашист кабахәтләр үзләре оккупацияләгән районнардан меңнәрчә совет кешеләрен Германиягә каторгага алып киткәннәр. Гитлерчылар бик күп русларны, украинлыларны, белорусларны концентрация лагерьларына япканнар, ә башкаларын кулакларга һәм алпавытларга коллыкка биргәннәр. Наумцевның немецларга коллыкка эләккән кызы үзенең анасына, Ворошиловград өлкәсенең Ровеньки шәһәренә менә болай дип язган: «Кадерле әнием, мин байда торам. Семьясы зур: түгел, үзләре икәү, бер балалары бар. Ләкин миңа эш муеннан. Иртән сәгать 5 тә торам, төнге 10 да ятам. Эшли башлаганнан бирле бары бер тапкыр гына, якшәмбе көн, лагерьга үзебезнекеләр янына җибәрделәр. Мин ярты сәгать соңга калып кайттым. Әни, хуҗаның минем йөземә ничек сукканлыгын, чәчләремне йолкыганлыгын мин бөтен гомеремә дә онытмам. Мин нәрсә эшлим инде? Өйгә җибәрмиләр, ә артык түзәрлек хәлем юк. Көн саен җылыйм. Инде бер генә котылу юлы бардыр—үз-үземне үтерү генә. Әни, җаным, мине исән килеш күрәсең килсә, бу коллыктан коткар. Гомерем булса, сиңа рәхмәтләр укырмын».

Фашист кол биләүчеләр үзләре тарафыннан Германиягә каторга эшләренә ирексезләп алып кителгән кешеләрнең маңгай тире һәм каны белән яшәргә телиләр. Ләкин алар совет кешеләрен кол итә алмаслар. Фашист кабахәтләр совет гражданнарының барлык газапланулары өчен үзләренең каннары белән түләрләр.

* * *

Гитлерчыларның котырган терроруна да карамастан, немец оккупантларга каршы Голландия патриотларының көрәше бер генә көнгә дә тукталмый. Роттердамда бер группа кораллы голландиялеләр немецларның һава һөҗүме оборонасы постына һөҗүм иткәннәр, 9 гитлерчыны үтергәннәр һәм бер зенит орудиесен сафтан чыгарганнар. Көндез урамда немецларның бер дингез офицерын револьвердан атып үтергәннәр. Гаагада патриотлар немецлар часте штабына бомба ташлаганнар

11 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

11 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

10 нчы мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның кимендә 10 танкысын һәм бронемашинасын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 150 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 8 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Сычевкадан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган берничә дистә пунктны һәм шул исәптән район үзәге Андреевскоены алдылар. Безнең гаскәрләр дошманның 14 орудиесен, 20 минометын, 100 дән артык пулеметын һәм 2.000 гә якын солдат һәм офицерларын юк иттеләр. Тулы булмаган саннарга караганда, немецларның 14 танкысы, 8 орудиесе, 25 минометы, 42 пулеметы, 500 дән артык винтовкасы, 2 сугыш припаслары склады һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдереп, халык яши торган 16 пунктны алдылар. 600 дән артык гитлерчы юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Бер участокта дошманның бер батальонга якын пехотасы безнең һөҗүм итеп баручы подразделениеләребезгә контратака ясарга маташкан иде. Дошман контрудар белән алып ташланды. Безнең сугышчылар, чигенүче гитлерчыларның артларыннан куып барып, халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр. Штык сугышыннан соң бу пункт немецлардан чистартылды.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманның көчле атакаларын кире кайтардылар. Зур югалтуларга да карамастан, гитлерчылар яңадан-яңа частьлар китерәләр һәм ничек кенә итеп булса да шәһәргә үтеп керергә маташалар. Сугышлар бик каты бара. Безнең частьлар дошманның атакаларын нык торып бер-бер артлы кире кайтаралар. Немецларның бер батальоннан артык пехотасы, 15 танк ярдәме белән, өлкән лейтенант Шеронин командалыгындагы взвод саклап тора торган бер авылга һөҗүм итте. Тигезсез көрәштә безнең сугышчылар группасы, танкка каршы ата торган пушка уты белән, немецларның 7 танкысын юк итте һәм 100 гә якын гитлерчыны кырып ташлады. Пушка сафтан чыкканнан соң сугышчылар, гранаталар ыргытып, дошманның тагын 3 танкысын зарарладылар. Н-че берләшмә участогында 700 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары кырылды, дошманның 11 танкысы, 4 самоход орудиесе һәм 20 автомашинасы юк ителде.

* * *

Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Район үзәге Красноармейскаяны алган чакта совет подразделениеләре 400 дән артык гитлерчыны кырдылар һәм 315 автомашина, 8 тягач, 570 тимер юл вагоны, 17 паровоз, күп кенә кораллар һәм сугыш припаслары кулга төшерделәр.

Һава сугышларында безнең очучылар немецларның 15 самолетын бәреп төшерделәр. Шуның өстенә дошманның бер самолетын совет зенитчиклары юк итте.

* * *

Смоленск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның халык яши торган бер зур пункттагы гарнизонына һөҗүм иткән. Совет патриотлары 100 дән артык гитлерчыны кырып ташлаганнар. Икенче бер отрядның патизаннары немецларның 4 тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә 4 паровоз һәм фронтка бара торган немец солдатлары һәм сугыш техникасы төялгән 42 вагон һәм 9 платформа җимерелгән.

* * *

Немецларның 337 нче пехота дивизиясенең 690 нчы полкының 6 нчы ротасыннан плен алынган ефрейтор Эдмунд Фишер болай диде: «Безнең ротаның командиры обер-лейтенант Греффер дивизия командирының бер приказын игълан итте. Приказда түбәндәгеләр әйтелгән иде: «Солдатлар үзләренең позицияләреннән чигенергә мәҗбүр булган чакта халык яши торган барлык пунктларны яндырырга һәм мөмкин булган бөтен нәрсәне юк итәргә кирәк. Калдырыла торган шәһәрләрнең һәм авылларның гражданнар халкын ирексезләп тылга күчерергә. Каршылык күрсәтүчеләрне кызганып тормыйча юк итәргә». Немецларның 5 нче танк дивизиясенең 14 нче гренадер полкының 5 нче ротасыннан плен алынган солдат Францишек Гмуздек болай диде: «Фронтның үзәк участогында немец властьлары бөтен гражданнар халкын ирексезләп тылга күчерергә тырышалар. Вязьма районында мин немец солдатлары сакчылыгы астында бара торган бик күп картларны, хатын-кызларны һәм балаларны күрдем. Авылларда сыкрану һәм елау хөкем сөрә. Берәүне дә калдырмыйча, барын да куып алып китәләр. Смоленскида эвакуацияләнгән руслар өчен җыелу пункты бар. Бу гаять зур лагерь чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган, һәм аны гаскәрләр һәм полиция бик нык саклап тора».

ВЛКСМ НЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ДЕЛЕГАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

ВЛКСМ ның VI нчы Казан шәһәр конференциясе 1943 нче елның 14 нче мартында, көндез 12 сәгатьтә, Менжинский исемендәге клубта (Карл Маркс урамы, йорт номеры 26) ачыла.

Ленин районы һәм Киров районы делегатлары регистрацияне ВЛКСМ райкомнарында үтәләр, калган районнарның делегатлары ВЛКСМ Шәһәр Комитетында һәр көн 10 сәгатьтән 22 сәгатькә кадәр үтәләр.

ВЛКСМ ның ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ.

АТ КАРАУЧЫЛАР ЯРЫШЫ

Кайбыч районының Мәлки һәм Мөрәле МТС политбүлекләре, Столбище районының Столбище МТС политбүлеге ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карарларын өйрәнү өчен колхоз ат караучыларының махсус җыелышларын үткәрделәр.

Столбище МТС ы хезмәт күрсәтә торган колхозларның ат караучылары җыелыштан соң шул ук районның Константиновка МТС ы хезмәт күрсәтә торган колхозлардагы ат караучыларны социалистик ярышка чакырдылар. Язгы чәчүгә атларны үрнәк булырлык итеп әзерләү һәм, гомумән, атларның тәрбия ителүен яхшы итеп оештыру социалистик ярышның төп пункты итеп алынды.

Франциядә гитлерчы оккупантларга каршы көрәш

ЛОНДОН, 10 март. (ТАСС). Англиянең информация министрлыгының хәбәр итүенә караганда, Франциядә Германия предприятиеләренә мәҗбүри эшкә җибәрү өчен яшьләргә мобилизация игълан ителгәннән соң немецларга каршы партизаннарның көрәше тагын да көчәйгән. Брестта бер группа француз патриотлары Германия солдатларына һәм офицерларына билгеләнгән киногa һөҗүм ясаганнар. Патриотлар залда булган немецларга берничә кул гранатасы ыргытканнар. Үлүчеләр һәм яраланучылар бар. Шул ук көнне Франция патриотларының икенче бер группасы шәһәрнең баш почтасын саклаучы немецларга һөҗүм иткән, ике солдатны үтергән. Брестта немецларга һөҗүм итүләр ачыктан-ачык урам бәрелешләре төсенә кергән.

«Марсейез» газетасының язуынча, Нанси якынындагы Туль шәһәрендә немец солдатлары отрядына граната ыргытканнар. Күп солдатлар үлгән һәм яраланган.

Сугышучы Франция штабының хәбәр итүенчә, шушы көннәрдә патриотлар ешкына немец хәрби хезмәткәрләре кереп йөри торган йорттагы казинога кул гранаталары ыргытканнар. 23 немец офицеры үтерелгән.

ГЕРМАНИЯ САМОЛЕТЛАРЫНЫҢ ШВЕЦИЯ ЧИГЕННӘН ОЧУЛАРЫНА КАРШЫ ШВЕЦИЯНЕҢ ПРОТЕСТЫ

СТОКҺОЛЬМ, 10 март. (ТАСС). «Стокһольм тиднинген» газетасының язуынча, Швециянең Берлиндагы илчелеге, Германиянең бер самолетының 6 нчы мартта Швеция чигеннән очып үтүенә каршы, Швециянең чит ил эшләре министры тапшыруы буенча протест белдергән.

Швециянең оборона штабының һава һөҗүменнән саклану бүлеге 8 нче мартта Германия самолетларының Сконеның көнчыгыш яры районында, шулай ук Сирисхамн белән Карлисхамн арасында Швеция өстеннән тагын берничә тапкыр очып үткәнлекләрен хәбәр итә.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 10 март. (ТАСС). Англиянең информация министрлыгының хәбәр итүенчә, 9 нчы мартта көндез Англиянең «Спитфайр» истребительләре Төньяк Франциягә берничә тапкыр һөҗүм ясаганнар. Шул көнне кич белән Англиянең «Маскито» бомбардировщиклары Ла-Манш якынындагы тимер юл үзәгенә һөҗүм иткәннәр. Бомбага тотудан шартлаулар булганлыгы беленгән.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 14 нче мартта кич — **«Таймасовлар»**.

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген — **«Башмагым»**, 13 нче мартта — **«Травиата»**.

Зур драма театры. Бүген—**«Маскарад»**, 13 нче мартта **«Испан священнигы»**.

Яшь тамашачылар театры. Бүген һәм 13 нче мартта кичке 7 сәгатьтә — **«Москвичка»**.

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы. Җанварлар өйрәтүче А. Н. Корнилов Һиндстан филләре белән катнаша.

Татарстан дәүләт филармониясе. Бүген—Менжинский исемендәге клубта скетчлар кичәсе. 8 сәгать 30 минутта башлана.

«Электро» көндез — **«Кино-концерт»**, кич — **«Җиңелмәслекләр»**, «Унион»— **«Степан Разин»**, «Пионер» көндез— **«69 нчы параллель»**, кич — **«Хатыннар»**. «Чаткы» — **«Котовский»**.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 101 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 403